**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Үчәлле авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Үчәлле авылы №69 25 сентябрь 2017 ел

Үчәлле авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Үчәлле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы, «Референдум үткәрүне башлап җибәрү турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 11 сентябрендәге 12 номерлы карарын «Референдум үткәрү инициациясе турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Советының 2017 елның 11 сентябрендәге 67 номерлы карары нигезендә,

Үчәлле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Үчәлле авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны түбәндәгечә расларга:

“2018 елда үзара салым кертүгә Үчәлле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә ризалыгыгыз бармы? Укуның көндезге формасында укучы студентлардан, 1 төркем инвалидлардан тыш, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1) җирлекнең торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (юлларга вак таш түшәү җайланмасы);

2) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (лампалар, урам яктырткычлары сатып алу һәм алыштыру, авыл җирлеге эчендәге юлларны кышкы чистарту, агачларны кисү, үлән чаптыру);

3) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү (янгынга каршы инвентарь сатып алу);

4) ритуаль хезмәтләр оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту (күмү урыннарын (зиратларны) карап тоту һәм ремонтлау, кадастр эшләре комплексы);

5) ял итүне оештыру һәм җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру (бәйрәм чараларын үткәрүне оештыру).

«КАРШЫ» «РИЗА».

3. Карар районның “Маяк” газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә түбәндәге веб – адресы буенчаhttp://aznakyevo.tatarstan.ru урнаштырыла.

4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис Г.М. Төхвәтуллина